ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексын гамәлгә кертү хакында» 2001 елның 30 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законның $1^2$ статьясы нигезендә рәсми бәяләмә алу өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенә җибәрергә.

3. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Хөкүмәтеннән рәсми бәяләмә алганнан соң Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

4. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына сайланган депутатларга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

5. Күрсәтелгән закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт

Советыннан рәсми вәкил итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 11 июне
№ 969-VI ДС